КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 17 гыйнвар г.Казань № 11

2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасында студентлар һәм яшьләр хезмәт отрядлары эшчәнлеген үстерү концепциясен раслау турында

Татарстан Республикасында студентлар һәм яшьләр хезмәт отрядлары эшчәнлеген үстерү өчен шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасында студентлар һәм яшьләр хезмәт отрядлары эшчәнлеген үстерү концепциясен (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына бу карар белән расланган 2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасында студентлар һәм яшьләр хезмәт отрядлары эшчәнлеген үстерү концепциясен тормышка ашыру чаралары планын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында студентлар һәм яшьләр хезмәт отрядлары эшчәнлеген үстерү концепциясен раслау турында» 2014 ел, 25 июль, 537 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин